СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

НУРЛАТ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА НУРЛАТСКОГО РАЙОНА.

*14 август, 1998 ел.*
*ҖОМГА*

*Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга.* | *№ 92 (8249)* | *Бәясе билгеләнгәнчә*

## КАФЕ ЭШЛИ

Мәдәният йортының өске катында колхозыбыз кафесы урнашкан. Кафеның ачык тәрәзәсеннән музыка агыла. Биредә бай тәҗрибәле Сания Галиуллина хезмәт күрсәтә. Ул үз кул астында эшләүче Люция Зиннәтуллина һәм практика үтәргә кайткан Ләйсән Сәлаховаларны бу хезмәтнең серләренә өйрәтә. Хәзер алар басуда игеннәрне җыючы механизаторлар өчен аш - суны тәмле итеп, җиренә җиткереп әзерлиләр. Һәм һәр көнне игенчеләрдән, биредә тукланучылардан күпме рәхмәт ишетәләр. Ашыгыз тәмле булсын, йөзегез якты булсын, ак халатлы уңган аш - су осталары.

**З.ИСМӘГЫЙЛЕВА.**
**Кычытканлы авылы.**

## Урак батырсыз узмас

**"Кондырча"**дан **Нәфис Мирсәет улы БИКБАЕВ** ДТ - 75 агрегаты белән бер көндә 59 гектарда арыш чәчеп, смена нормасын 211 процентка үтәде.

***

**"Рассвет"**тан **Фәйзулла Хәйрулла улы БИКИНЕЕВ** шундый ук агрегат белән шул ук эштә смена нормасын 182 процентка башкара.

***

Шул ук хуҗалыктан **Камил Минхәер улы ГЫЙБАДУЛЛИН** Т- 4 тракторы белән туңга сөрүдә смена нормасын 175 процентка үти.

***

**"Үрнәк"**тән **Ильяс ФӘССАХОВ** К - 700 тракторы белән туңга сөрүдә смена нормасын 168 процентка башкарды.

***

**Синдряков исемендәге** хуҗалыктан **Андрей Валентинович РОДИОНОВ** ЖВН - 6лы "Нива" комбайны белән донник урдыруда смена нормасын 127 процентка үти, бу сезонда барлыгы 350 гектарда эш башкарды.



*Таныш булыгыз: "Киекле" КХАсы бозау караучысы Әминә Юныс кызы ХӘЛИМУЛЛИНА.*

*Әминә Юнысовна терлекчелектә байтактан эшли. Күндәмлеге, сабырлыгы, эш сөючәнлеге белән хезмәттәшләре арасында аерым бер хөрмәт казанды ул. Быел терлекче профилакторий группасында бозаулар карый, аларны сау - сәламәт үстерү өчен көчен кызганмый. Шуңа эшенең нәтиҗәсе дә әйбәт: маллар арасында үлем - китем юк, аларның тәүлеклек артымы 800 граммнан да ким булмый.*

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

## ***Авыл яшьләр белән матур***

## МЕХАНИЗАТОР ҺӨНӘРЕ АБРУЙЛЫМЫ?

***Авгүстның бер эссе кичендә Бикүле авылы мәдәният йорты утлары яктырак янып, ишекләре киң итеп ачылды:ул кич шул һәм тирә - як авыллардан килгән алдынгы яшь механизаторларныкы иде. Алар - "Үрнәк" кооператив хуҗалыгыннан комбайнчылар Ришат Идиятуллин, Марат Хәйдәрҗанов, тракторчы Фәнил Мотыйгуллин, Муса Җәлил исемендәге хуҗалыктан комбайнчы Марат Гатин, механизатор Якуб Әхмәтсәгыйров, "Игенче"дән механизаторлар Радик Гайнуллин, Рәмис Ситдыйков һәм "Чирмешән"нән комбайнчы ярдәмчеләре Рәфис Садыйков, Илнар Хәснуллин һәм Илдар Насыйбуллин.***

- Яшь механизаторларны очраштыру, сәхнәгә күтәреп хөрмәтләү кичәсе комбайнчы, механизатор кебек гаять авыр, чиксез җаваплы һөнәр ияләрен мактау, гомумән, бу һөнәрнең абруен, дәрәҗәсен күтәрү максатыннан чыгып оештырылды, - дип сөйли кичәне оештыручы һәм Бикүле мәдәният йорты директоры Асия Ибраһимова белән бергәләп аны алып баручы район яшьләр бүлеге мөдире Рәмис Бикинеев.

Ә менә үз һөнәрләре турында механизаторлар үзләре нинди карашта соң? Кичә барышында сорауларга җаваплар рәвешендә бу хакта һәркем үз фикерен, үз мөнәсәбәтен җиткерә алды. Игенче, авыл механизаторының эшчәнлегендә елдан - ел киртәләрнең үсүенә, кыенлыкларның өстәлүенә карамастан:

- Яраткан һөнәрем белән шөгыльләнүемне мин бәхет дип саныйм,- ди Якуб Әхмәтсәгыйров. - Улларымның да минем эздән китүенә мин шат кына булачакмын.

Кәкре Атау егете Илдар Насыйбуллин аңардан яшьрәк, комбайнда эшләү стажы да зур түгел. - Кичләрен, яшьтәшләрең клубта күңел ачып йөргән чакта, гарьләнеп кырдан, комбайн гөрелтесеннән качып китәргә теләгән чакларың булмыймы?

- Юк, һич юк. Киләчәктә шофер булырга телим,- ди ул.

Яшь механизаторлар хөрмәтенә район үзешчәннәре җыр, бию белән җылы теләкләрен юлладылар. Нурлаттан Роза Әхмәтҗанова, Люция Җиһаншина, Тәлгать Бәдыйгин килгән иделәр, шулай ук Бикүле һәм Кәкре Атау, Зирекле авылы үзешчәннәре - Бибинур Әбделвәлиева, Хәмдия Гыйләҗева, Илшат Әһлиуллин, Рәсимә Гыйләҗева, Гөлсәрия Вәлиуллина һәм Илназ Алишев та урак алдынгыларын котладылар. Хуҗалык җитәкчеләре исеменнән аларга бүләкләр тапшырылды. Тик менә алдан чакырулы булуга карамастан, 4 хуҗалыктан бер генә рәис тә игенче хезмәтен хөрмәтләүгә багышланган кичәгә килергә җай тапмаган иде.

Очрашуны оештыруда ярдәм күрсәткәннәре өчен район яшьләр бүлеге Бикүле мәктәбе директоры Г.Камаловка һәм шул ук хуҗалык рәисе Ф.Мингалимовка олы рәхмәтен ирештерә.

***

Август ахырларында Бикүле авылы тамашачылары тагын да күңеллерәк һәм шаянрак кичә көтә. Яшьләр бүлеге биредә Бикүле, Кәкре Атау, Чулпан авыл яшьләре катнашында Шаяннар һәм Тапкырлар Клубы (КВН) ярышы үткәрергә ниятли.

**Ф.ГАЛИМОВА.**

## АШАГАН МАЛ ГЫНА АРТЫМЛЫ

***Саннарның беренче баганасы - 7 айда, икенчесе - июльдә мөгезле эре терлекләрдән алынган тәүлеклек артым (граммнарда).***

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| "Таң" | 610 | 853 | "Сөлчә" | 494 | 477 |
| "Дуслык" | 610 | 529 | "Родина" | 492 | 371 |
| Шикәр заводы ярд. хуҗ. | 574 | 214 | "Чирмешән" | 482 | 272 |
| "Рассвет" | 568 | 623 | "Татарстан" | 478 | 444 |
| Синдряков исем. | 562 | 596 | "Алга" | 450 | 433 |
| "Игенче" | 561 | 700 | Хафизов исем. | 430 | 400 |
| М.Җәлил исем. | 548 | 543 | РСУ ярд. хуҗ. | 429 | 680 |
| "Кондырча" | 544 | 495 | "Нур" кооп. | 423 | 355 |
| Мичурин исем. | 536 | 573 | Илюткино - 2 | 422 | 677 |
| "Комбайн". | 526 | 357 | "Чулпан" | 410 | 368 |
| "Заветы Ильича" | 519 | 478 | Илюткино - 3 | 401 | 619 |
| "Киекле" | 513 | 597 | "Үрнәк" | 379 | 469 |
| Кузнецов исем. | 510 | 438 | "Берлек" кооп. | 378 | 305 |
| "Заря" | 507 | 523 | "Руслан" кооп. | 300 | 286 |
| "Төрнәс" | 507 | 346 | | | |
| Нефтебаза ярд. хуҗ. | 495 | 452 | **Район буенча** | **506** | **489** |

Ел ахырына таба иткә сорау тагын да артыр дип фараз ителә һәм бүген маллары ишле булып, аларны әлегә арзанлы азык белән көрәйтеп калган хуҗалыклар терлекләрне абзарларга кайтаргач та отачаклар гына. Ул яктан район буенча мөгезле эре терлекләрнең баш саны әлегә былтыргыдан азрак булса да, үстерү һәм симертүдәге маллардан үрчем алу ягыннан бераз алга китеш бар. Җиде айда уртача тәүлеклек артым узган елдагыдан 20 граммга күбрәк булды. Малларның үлем - китеме дә узган елдагыдан азаюын исәпкә алсак, ит җитештерү өлкәсендә хәл начар түгел.

"Комбайн"да тәүлеклек артымны былтыргыдан берьярым тапкырга, Муса Җәлил исемендәге, "Игенче", "Заря", сөт - май комбинаты ярдәмче хуҗалыкларында 19 - 32 процентка арттыра алдылар. Ә менә "Алга"да, киресенчә, 26 процентка чигенеш ясалды. "Агрохимсервис" ярдәмче хуҗалыгының кооперативларында да хәл мактанырлык түгел әле. Артым алу буенча алда баручы "Дуслык"та да былтыргыдан чигенеш саллы.

Үстерү һәм симертү малларын тук тоту ит җитештерү белән бергә таналарны каплатуга әзерләү җәһәтеннән дә мөһим бит, ә анысының әһәмиятен аңлатып торасы юк. Шуңа күрә бу төркем маллар аерым игътибар үзәгендә булырга тиеш бүген.

## АВЫЛЫМ КҮҢЕЛЕН ТӨШЕРМИ

"Халык тырышлыгын зур батырлыкка саныйм мин, - диде "Кондырча" күмәк хуҗалыгының баш бухгалтеры Хәлил Хәмзиевич Шәйхетдинов Түбән Нурлат кешеләренең бүгенге эш - мәшәкатьләре турында сөйләшүебезнең башында. - Уҗым культуралары күптән суктырылды. Инде сабан ашлыгының уңышы җыеп алынган мәйданнар да ишәя бара. Елына күрә ярыйсы гына уңыш чыга, гектардан 25 центнер булыр һәм үз ихтыяҗыбызны канәгатьләндерергә җитәр. Безнең максат - бар булганын югалтуларсыз, түкми - чәчми, тиз арада җыеп алу, - ди баш белгеч.

Шуның өчен бригадада ике сменалы эш оештырылган. Икенче сменада күбрәк туңга сөрү, уҗым чәчү өчен җир әзерләүгә зур игътибар бирелә. Сөрүне сентябрьгә бетерергә уйлыйлар.

Әйе, фидакарь җанлы игенчедән көч - куәт, күпме энергия сорый шул кызу урак өсте. Үзләрен аямыйча, җаннары - тәннәре белән бу эшкә бирелгән батыр йөрәкле механизатор, комбайнчыларның исемнәрен атап үтәсем килә. Әсхать абый Тямаевның уракта өлеше бик зур. Һәр елны иң алдынгы бара ул комбайнында. Эшкә карашы җитди. Уңган кеше генә түгел, шул ук вакытта ул холыклы, акыллы кеше. Аның техникага карашы да үзгә, техника телен белә, диләр.Фәрит Абдуллин исемен телгә алмасам да хата булыр. Язын 800 гектар җирдә төрле культуралар чәчкән ул, чәчү бетүгә, пар җирләрен эшкәртүгә тотынган. Хәзер дә тракторының бер туктап торганы юк. Азык хәзерләүдә Минияр Бакиров алыштыргысыз. Катлаулы техника "Полесье"ны үз ихтыярына буйсындыра ул. Тәҗрибәле булуы исәбенә генә җиңә, башка берәү дә аның кебек ипле эшли алмый анда, диләр. Быел хуҗалыкта кукуруз әйбәт һәм Минияр абый ярдәмендә аны тизрәк җыеп алырга исәп тоталар.

Шикәр чөгендеренә дә зур өмет баглыйлар. Быел беренче тапкыр Француз технологиясен кулландык, үзен аклый, диләр: беренчедән, хатын - кызларны авыр физик хезмәттән коткара, икенчедән, арзанга төшә.

Мастерскойдагы эшчеләр дә уңышны тиз арада җыюда зур роль үтиләр. Бу яктан Салих абый Гомәров исемен аерым әйтеп үтәсе килә. Хәзерге хуҗасызлык хөкем сөргән заманда күрше Самара өлкәсеннән беркемгә дә кирәкмәгән ватык техниканы эзләп табып алып кайтып, барлап, ике трактор җыя ул, бер эскерт өйгеч көйли.

Күпме генә төзек техника булмасын, матур сүзләр сөйләнмәсен, халыкта эшләү рухы булмаса, зур нәтиҗәләргә ирешү мөмкин булмас иде. Акчасын вакытында алмаса да крестьянның өмете сүнмәгән әле. Эшли ул, үземә булыр, үзем өчен тырышам диеп көне - төне тирен түгә. Дөрес, Хәлил Хәмзиевич та, көчебездән килгән кадәр булышабыз, хезмәт хакы исәбенә итен, онын, колбасасын бирәбез, утын кайтартабыз, диде... Баш белгеч киләчәккә планнары белән дә бүлеште. Түбән Нурлат зур юл өстендә. Авыл янында гына кафе - магазин ачарга ниятләп торалар. Үзләрендә булган малдан юлчыларны кайнар өчпочмак, тәмле чәй белән сыйламакчылар.

Әйе, авыл халкы, авыл кешесе, нәрсә генә күрмәсен, кичермәсен, җиңелүче булып чыкмаган. Бу авыр заманда да уңышлар сезгә, кадерле игенчеләр, ходай авыр көннәрдә сабырлык, күңел күтәренкелеге бирсен.

**Люция СӘЙФЕТДИНОВА,**

**КДУның журналистика факультеты талибәсе.**

# БАР ШУНДЫЙ ҮЗӘК

Инвалидларны реабилитацияләү буенча республика үзәге Казаннан ерак түгел Идел буенда, нарат урманы эчендә урнашкан. Табигатьнең хозурлыгы, һавасының сафлыгы үзләре генә дә мең чирдән шифа булырлык бу үзәктә балалар церебраль параличы (ДЦП), инсульт, имгәнүләр, нерв авырулары нәтиҗәсендә гариплеккә чыккан кешеләр дәвалана. Үзәк беренче пациентларын 1990 елда кабул итә. Ул чорда заманында өлкә комитетының "беренче" кешеләре өчен махсус төзелгән ял базасын инвалидларны реабилитацияләү үзәге итү зур җиңү була. Бу эшләр Үзәкнең баш табибы, медицина фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасының баш реабилитологы Вәлидә Гаделевна Исанова тырышлыгы белән башкарылган. Шул чорда тупланган 80 кешелек коллектив бүген дә эшен әйбәт кенә дәвам итә. Ел саен 500ләп авыру дәвалана, сәламәтлеген ныгыта икән биредә. Күбесе "стажлы" дәваланучылар.

- Начар җиргә кеше икенче тапкыр килми инде,- ди **Арчадан Миләүшә ханым**.- Беренче тапкыр узган ел, улым машина астына эләгеп катлаулы операцияләр кичереп озак кына дәваланганнан соң ДРКБдан җибәрделәр. Булат йөрү түгел, утырып та тора алмый, сөйләшүенең дә рәте юк иде. Хәзер, әйтмәгәнем булсын, йөгереп кенә йөри, әйбәт сөйләшә. Менә тагын бер айга калып булмасмы дип торабыз әле дә... ничек булыр.

**Түбән Камадан Ольга** (ДЦП, 28 яшь):

- Минем бирегә сигезенче мәртәбә килүем. Рәхмәт врачларга, инструкторларга, һәр авыруны терелсен дип, тырышып дәвалыйлар. Елдан - ел үземне яхшырак хис итәм. Биредә үземә бик күп дуслар да таптым, күңелле яшибез.

**Володя дәдәй:**"Без кызым Галя, оныгым Алеша белән Нальчик шәһәреннән килдек. Бездә санаторий, ял йортлары күп булса да, бу үзәк кебеге юк. Баланның баласы балдан татлы, диләр бит, оныгымны тизрәк терелтәсем килә, гомерлек гарип булып калмасын иде",-ди.

Биредә авырулар дәвалану өчен бөтен шартлар да тудырылган. Дәвалауда массаж, дәвалау гимнастикасы, кондуктив терапия һәм кинезиотерапия ысуллары уңышлы файдаланыла. Үзәк белгечләре республикабызның танылган медицина галимнәре белән дә даими элемтәдә торалар, һәрчак киңәшләшеп эшлиләр. Республика клиник шифаханәсе табиблары да биредә үз кеше.

Мин булганда реабилитацияләү үзәге авыруларны дәвалау белән бергә күчену мәшәкатьләре белән дә яши иде. Моңарчы әфганчылар карамагында булган "Якташ" санаториена күчәселәр икән.

-Биредә җәйге чорда җәннәт булса да язгы - көзге- кышкы чорларда авыруларга дәвалау корпусына йөрү авырлаша. Биналарыбыз таралып утырган, юллары үр менеп үр төшәсе, ә "Якташ" махсус төзелгән санаторий - бөтенесе бер бинада булачак,- дип күчену сәбәбен аңлатты А.А.Зәбирова.

Санаулы вакыт тиз узды. Тәнгә сихәт, күңел күтәренкелеге алып кайтыр якка юл алдым.

Ә кулга каләм алуымның сәбәбе... шундый шәп Кырым, Сочи санаторийларына тиң реабилитацияләү үзәге барын республика районнарында яшәүче инвалидларның күпчелеге белеп бетермидер дигән фикердән, чөнки күпчелек дәваланучылар Казанда яшәүчеләр иде.

**Җ.ШАКИРОВ.**
**Кәкре Атау авылы.**

# ЯҢАДАН ТЕРКӘҮ БАРА

ТР Министрлар Кабинетының "Дини берләшмәләрне дәүләт теркәве турында"гы карары нигезендә районда мәчетләрне һәм чиркәүләрне теркәү дәвам итә. Барлык документлар пакеты ТР Юстиция министрлыгының теркәү палатасына 1999елның 15нче гыйнварена кадәр тапшырылырга тиеш. Шуңа карамастан, безнең район бу мәсьәләне күзгә хәл итәргә ниятли. Бүген безнең территориядә 27 мәчет, 3 чиркәү һәм 1 гыйбадәт йорты теркәлгән.

## 02. 02. 02. 02.

*Район газетасында "02 хәбәр итә" рубрикасы астында милиция яңалыклары белән таныштыруның халыкта гади кызыксыну тудыру максатында гына булмаганлыгы аңлашыладыр, мәгаен. Хокук бозу турында һәр конкрет вакыйгага намуслы гражданнар өчен гыйбрәт тә, ягъни закон аша чыкма, дигән сүз ул. Озак вакытлар буе бу рубрикага мөрәҗәгать итмәгәнгә, без бу юлы район һәм шәһәр эчке эшләр бүлеге начальнигы урынбасары, криминаль милиция начальнигы Валерий Леонидович ГАВРИЛОВка сүз бирергә кирәк дип санадык.*

# МИЛИЦИЯ ЙОКЛАМЫЙ

- Кызганычка каршы, районда оператив хәл кискен булып кала бирә. Милиция тарафыннан ачыклана торган хокук бозу очраклары шул хакта сөйлиләр. Августның Зеннән алып 5енә кадәр без Самарадан кайтарылып "кара" базарны тутырган начар сыйфатлы "Осетия" аракысын сатучыларны ачыклау һәм товарны әйләнештән алу максатында "Плотина" операциясе үткәрдек. Аның барышында җиңел кәсепчеләрнең Чулпан, Иглай, Заречный, Салдакай авылларында һәм, әлбәттә, Нурлатның үзендә күп булуы ачыкланды. Шуның өчен 20ләп кеше административ тәртиптә барлыгы 500 мең сумга якын (Россия Законы буенча) штрафка тартылды. Кабат тотылган очракта бу кешеләргә карата тагын да кискенрәк чаралар кулланылачак. Республика законы 25 (!) мең сумга кадәр (минималь сумма 14,5 мең сум) штраф салырга рөхсәт бирә.Барлыгы 35 әрҗә аракы алынды.

98нең җәе тагын бер куркыныч хәлне ачыклады: Заречный поселогында бер яшүсмердә бер килога якын киндер (наркотик матдә) табылды. Экспертиза үткәргәннән соң аңа карата җинаять эше кузгатылачак һәм РФ ҖКның 288 нче маддәсе нигезендә ул җәзага тартылачак,ә анда хокукыннан мәхрүм итүгә кадәр каралган.

Милициягә ял итәргә туры килми. Мәсәлән, 27нче июльдә төнге сәгать 11дә дежур частькә телефоннан шомлы хәбәр килеп ирешә: район үзәк хастаханәсенә Төрнәс авылыннан сул як боты утлы корал белән яраланган Н.ны китерәләр. Тикшерү - оператив группасы иртәнгә кадәр эшләп, Н.га Яр Чаллыдан килгән кешеләр атканлыгын ачыклый. Кичекмәстән атучыларның кемлеген белү максатында шул тарафларга оператив төркем җибәрелә. Нәтиҗәдә җинаятьтә катнашучы берәү тоткарланды, алга таба җинаятькә оеткы салучының эзенә төшәргә да шанс юк түгел. Алдан ук фараз ителгәнчә, бу криминаль ызгышу булмыйча, мәхәббәт "өчпочмагы"нда кризисны хәл итү булып чыкты. Гомумән, соңгы вакытта Төрнәс безгә күп борчу тудырды. Июльнең 20ләрендә шунда ук тоткынлыктан азат ителүенә бер ел да тулмаган маньяк Б. анда яшәүчеләрне, бигрәк тә, ялгыз карчыкларны куркытып йөри. Бер хатынны көчли. Милициягә хәбәр кергәннән соң 2 - 3 көндә Нурлат янындагы дачаларның берсендә ул кулга алына. Хәзер аңа карата җинаять эше кузгатылды.

*- Валерий Леонидович, яшьләр арасында хокук тәртибен саклауның торышы ни хәлдә? Бары да яхшы дип булмыйдыр, мәгаен.*

- Аеруча борчу һәм шомлылык белән (ата - аналарга да барып ирешсен иде) шундый хәл турында искәртәсем килә: элек булмаганча, яшүсмерләрдән наркотиклар алу (әлегә киндер генә) фактлары күп. Бу җәһәттән, махсус басым ясап әйтәм: наркотик кергән теләсә нинди матдәне әзерләү, саклау һәм тарату өчен җинаять җаваплылыгы каралган. Шуңа да ата - аналарны аеруча уяу булырга чакырам. Улыгызның яки кызыгызның законга каршы гамәлен сездән башка беркем дә туктата алмаячак һәм төзәтә алмаслык хатадан да саклап калмаячак. Эш милициягә барып җитә калса, бу инде профилактика түгел, ә җәза.

*- Авылда урак вакыты, бу чорда яңа уңышның файдасын күрергә теләүчеләр дә аз түгелдер. Бу вакытта милиция кая?*

- Урынлы сорау. Урып - җыю башлануга ук без янгын службасы белән берлектә махсус оператив - эзләү группасы оештырдык. Ул кырда, юлларда... яңа ашлык урлаучыларны ачыклау белән мәшгуль. Мондый фактлар бар да инде. Хәл бигрәк тә Яңа Әмзә авылында борчулы. Биредә күп кеше административ җәза алды. Ә берсенә карата җинаять эше кузгату хакында сүз бара. Иген урлаучыларны ачыклау буенча операция урак беткәнчегә кадәр дәвам итәчәк.

*- Соңгы вакытта бүлек гражданнарның законга каршы тагын нинди характерлы гамәлләренә игътибарны юнәлтте?*

- Аракы - шәраб белән сату итүдә билгеләнгән тәртипне бозу очракларын ачыклау максатында сәүдә нокталарын тикшерү барышында безнең хезмәткәрләр байтак кына срогы чыккан азык - төлек товарлары реализацияләнүенә тап булдылар. Ә бит бу халык сәламәтлегенә зур зыян китерә. Сәүдәгәрләр шуны истә тотсыннар иде: барлыгы 8,5 сумлык срогы чыккан товар табылган очракта да сатучы җинаять җаваплылыгына тартылачак, башка очракларда зур штрафлар каралган. Моннан башка безнең хезмәткәрләр агымдагы эш белән дә шөгыльләнәләр: гараж бикләрен җимереп автомашина урлау, ашханәләрдә угрылык фактлары булды. Соңгы вакытта хатын - кызлардан ирләре өстеннән гаризалар керде. Төрле сәбәпләр: кайда хулиганлык, ә кайда физик көч ярдәмендә мөнәсәбәтләрне ачыклау буенча 8 җинаять эше кузгатылды. Эчкечелек һәм эсселек - менә шул сәбәпләр көчле җенес вәкилләрен якыннарына карата явызлык кылырга мәҗбүр итә торгандыр, бәлки. Исерек килеш су коену буенча да рекорд куелды быел - барлыгы 17 кеше батып үлде. Эсселектән һәм спиртлы эчемлектән кызган кешенең тәне суда кинәт суыну нәтиҗәсендә ул шунда ук үләргә мөмкин. Кызганычка каршы, күпләр бу хакта оныталар.

*- Һәм соңгы сорау, Валерий Леонидович. Милициянең үзенә кагыла. Билгеле булганча, республика Эчке эшләр министрлыгы җитәкчелеген алмаштыру ведомствоның үзендә тиешле тәртип һәм законлылыкны булдыруга ныклы ориентация бирде. Будөрестер дә, бәлки. Таләпчәнлекнең артуы милиция сафларында да кыскартуларга китермәгәе. Бездә ничек тора бу мәсьәлә?*

- Бу бик борчулы һәм күптән хәл ителәсе адым. РФ һәм ТР Эчке эшләр министрлыгы җитәкчелеге тарафыннан милиция бүлекчәләрендә шәхси составны 10 процентка кыскарту турында карар кабул ителде. Без, беренче чиратта, эшлеклелек һәм мораль сыйфатлары буенча үз вазифаларын акламаган хезмәткәрләрне кыскартачакбыз. Күптән түгел шулай ике офицерны эштән азат иттек һәм бу аларның үз гаепләре аркасында булуын ассызыклап әйтәсем килә. Тагын бер офицер һәм сержантка кагылышлы тискәре фактлар бар. Яшереп торуның кирәге юк - алар эчкечелек, үз вазифаларын һәм хезмәт бурычларын намуслы үтәмәүгә бәйле. Ә бит алар милициянең абруен төшерә, шуңа да мондый хәлләр белән килешергә һич ярамый. Мин үзем шуңа нык ышанам: бүгенге авырлыкларга, аңлашылмаучанлыкларга карамастан, милиция югары сугышчанлыгын һәм оперативлыгын сакларга тиеш. Югыйсә, җәмгыять җәзасыз җинаятьчелеккә күмеләчәк. Ә аңа бары тик чиста куллы һәм ниятле, һөнәри әзерлекле, оператив - техник чараларның минимумы белән булса да тәэмин ителгән һәм, әлбәттә, тормыш тыллары өчен тыныч кешеләр генә каршы тора алачаклар.

*- Бу фикер белән килешмичә мөмкин түгел. шулай булсын дияргә генә кала. Ул чакта безгә, гади гражданнарга да ул кадәр шомлы булмас иде, бәлки...*

**Әңгәмәне Д.ТӘМАЕВА алып барды.**

# БЕРКЕТМӘГӘ КУЛ КУЕЛДЫ

6 августта көн буена Татарстан Хөкүмәтендә "Межрегионгаз" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять генераль директорының беренче урынбасары Ренат Байгузин җитәкчелегендәге Россия "Газпром" акционерлык җәмгыяте вәкилләре белән сөйләшүләр дәвам итте. Анда Татарстан вице - премьеры Ринат Гобәйдуллин, "Татгазинвест" ябык акционерлык җәмгыяте җитәкчесе Ренат Ханбиков, республиканың эре предприятиеләре җитәкчеләре катнашында газ өчен түләү юллары тикшерелде. Сөйләшүләр беркетмәгә кул кую белән тәгәлләнде.

Билгеле булганча, узган елның көзендә Татарстан Хөкүмәте белән "Газпром" арасында килешүгә кул куелган иде. Шуның нәтиҗәсе буларак, безнең республикада газ кулланучылар белән әлеге акционерлык җәмгыяте арасындагы мөнәсәбәтләрнең кризислы үсешен туктатып булды. Ләкин килешүне үтәү зур кыенлык белән барды. Сәбәбе мәгълүм: илдә финанс - икътисадый кризисның тирәнәюе.Шул вакытлардан бирле элеккеге бурычларга яңалары өстәлде. Бер яктан, Федераль салым хезмәте басымы астында, икенче яктан, эш хакы түләүне таләп итүче үз эшчеләре басымы астында эшләүче "Газпром" газ кранын яңадан яба башлады.

Рәсми булмаган фараз буенча, Р.Байгузин Казанга Татарстанның яңа Премьер - министры Рөстәм Миңнеханов белән шәхсән танышу өчен килгән. Берничә сәгать эшлекле сөйләшү Рөстәм Нургалиевичка һәм Ренат Нургалиевичка уртак тел табарга, проблемаларны үзара аңлауга килергә ярдәм итте. Татарстан предприятиеләренең бурычларын түләүнең мөмкин булган барлык вариантлары җентекләп каралды. Мәсәлән, "Газпром"ның Россия бюджеты алдындагы йөкләмәләрен, ә Россия бюджетының безнең республика предприятиеләре алдындагы йөкләмәләрен "бөҗралау" турында сүз барды.Түләү Россия акционерлык җәмгыяте системасында файдаланыла торган продукция исәбенә дә кабул ителәчәк. Казан "Органик синтез" акционерлык җәмгыятенең полиэтиленына аерым кызыксыну белдерелде. Дөрес, ул "Газпром" алдында бурычлы түгел. Аның каравы, "Татэнерго" предприятиесенә бурычлы. "Татэнерго"ның да, үз чиратында, газ өчен түлисе күп. Әлмәт торба заводына да заказлар урнаштырылачак.

Боларның бөтенесе бурычларга кагыла. Ә "зәңгәр ягулык" өчен агымдагы түләүләр тулысынча капланырга тиеш. Өстәвенә, 30 процентын "тере" акча белән түләргә кирәк. Республикага газ җибәрүне киметерләрме? Россия акционерлык җәмгыяте ягыннан әлегә кискен хәрәкәтләр көтелми, дип әйтергә мөмкин. Ләкин, Р.Байгузинның әйтүенчә, түләнәчәк газ гына җибәреләсе.

**Ә.МАЛИКОВ.**
**("Ватаным Татарстан"-нан).**

### Бер йортның хәлләре

# ВӘГЪДӘ ИСКЕРӘ, БОРЫНГА ИС КЕРӘ

***Төзүчеләр микрорайонының Циолковский урамындагы 9 нчы йорт янында чишмәләр бәреп ята, тик йорттагы халык кына моңа бер генә дә шат түгел. Ник дисәң, суы бик тә "хуш исле" шул.***

***Дөрес, кызуда сусызлыкка, салкында өенең җылытылмавына күнгән безнең халык мондый гына "чүп" нәрсәгә күнә дә күнә инде ул. Тик адәм баласының түземлегенең дә бер чиге була бит. Менә бу йортта яшәүчеләр дә МППга да, санэпидкүзәтү үзәгенә дә мөрәҗәгать итеп карыйлар. Безгә, редакциягә дә шалтыраттылар: "Җитәкчеләр район гәзитен укымый калмый торганнардыр, Безнең башка төшкән бу бәлагә дә игътибар итәрләр бәлки. Ишегалды буйлап җәен генә түгел, кышын да су агып ята бит. Гыйнварда боз ананас төсенә керә, ә хәзер бу суга бакалар да ияләште инде..."***

Бу йортның тарихы бик гадәти. Бер ел элек НГЧ, коммуникацияләр буенча килешенгән эшләрне үтәп, аны МПП кулына тапшырган. Дөрес, җитешсезлекләр бүген аз түгел әле, тик халык аларына гына түзә инде. Бирелә яшәүчеләрнең бар бәласе шунда ки, йорт авышлыкта урнашкан, һәм аңардан өстәрәк төзүчеләрнең Мәскәү урамына урнашкан 5 нче йорты тора. Нәкъ менә шул йортның канализация коелары ташып чыгып аккан шакшы су бо-рга таба агып килә дә инде. Халык нәфрәтләнә, билгеле, кайберәүләр тиешле инстанцияләргә барып дау кузгатырга кирәк диләр, "тешлерәкләре" исә, мондый хәл берәр түрәнең гүрничәсе янында булса, әллә кайчан техникасы да, эшче көче дә табылыр иде инде, дип сөйләнәләр. Тик менә аларның хәленә кем керер соң?

Ә теге суның тирә - юньгә тарала торган исе һич тә хушбуй исе түгел. 5 нче йортның подвалы шакшы су белән тулып торганда анысы гаҗәпмени? Сасы газ чыгарып яткан шул суга тагын чебен - черкиен дә кушсаң... Дәүләт санэпидкүзәтү үзәгенең коммуналь гигиена буенча табибы ярдәмчесе Луиза Рөстәм кызы Камалетдинова әйтүенчә,болар һәммәсе паразитар һәм йогышлы авырулар барлыкка килүенә сәбәп булырга мөмкин. Шуңа күрә көзгә кадәр подвалдан суны суыртып, аны (кулдан) чистартып чыгарга, сүүткәргечне, канализация системасын тәртипкә китерергә, дезинфекция ясап, подвалга керә торган ишекләргә рәшәткә куярга иде. Тик нинди көч белән?

- МСОның 26011,3 квадрат метр торак фондын үз балансыбызга алдык без, - ди МПП начальнигы Әнис Котдус улы Гайнуллин,- Министрлар кабинетының күрсәтмәсен үтәмичә ярамый. Тик документларга кул куйганда оешма җитәкчелеге тапшыру - кабул итү вакытында беренче чираттагы барлык чараларны үтәргә вәгъдә бирде. Аерым алганда, быелның 1 апреленә кадәр шушы һәм тагын берничә йортның подвалларындагы канализация системасы ремонтланырга тиеш иде. Хәзергә кадәр бер ни дә эшләнмәгән. МСО үз вәгъдәсен үтәсен әнә. Безнең үзебезнең генә көчтән килә торган эш түгел - бөтен шәһәр безнең җилкәдә бит.

Рәсми кабинетларның берсендә күрсәтеләр безгә ул килешүне.Чиновниклар телендә "МСО балансындагы торакны, инженерлык челтәрен һәм тышкы төзекләндерү объектларын МПП ЖКХсы балансына тапшыру шартлары турында техник киңәшмәнең беркетмәсе" дип атала ул. 1998 елның 16 гыйнварында төзелгән. Ике яктан да куллар куелган. Тик менә эш кенә урыннан кузгалмаган. МСО рәисе Рөстәм Мингалиевич Карама безнең белән әңгәмәдә дә үз вәгъдәсеннән баш тартмады, тик менә төгәл срогын гына әйтмәде, аннары, яз көне подвалны бер мәртәбә чистарттык инде, хәзер урамдагы канализация тыгылган, бөтен бәла шунда, дип өстәде.

**Әфәнделәр, әйдәгез инде, үле ноктасыннан кузгатып җибәрик шушы мәсьәләне! Уртак тел табыгыз инде. Йортларда әллә каян килгән халык түгел, үзебезнең кешеләр яши бит. Ул халыкны болай да еллар буе акча түләми интектерәбез, атлаган саен алдап киләбез. Әз генә тырышсак, шушы гади халыкка да кешечә яшәү шартлары булдыра алабыз бит инде. Өстән китереп кыссалар әллә ниләр эшлибез бит үзебез.**

**Т.НАЗАРОВА.**

---

### *Менә сиңа мә!*

## ӘЧКЕЛТЕМ ТӘМЛЕ "ТАТЛЫ ПАР"

***Июнь аенда район гәзитендә "Бер бушанып алыйк" дигән рубрика очраткан идем. Минем дә күңелемдә шундыйрак бер хәл саклана.***

Шулай бервакыт "Хуҗабикә" ("Хозяюшка") кибетенә кердем - әйберләре дә күп, мөгамәлә дә яхшы булганга шунда еш йөрим мин. Кырык яшьләрдәге бер хатын вагын - төяген сатып алып тора иде. Шул вакыт подвалга ике яшь кенә хатын - кыз килеп керде - күрер күзгә яшьләр, кием - салымнары да, тышкы кыяфәтләре дә бик тәртиптә. Тик... берәр генә минут түзеп тордылар да, кискен генә тавыш белән сатучыга эндәштеләр: "Болар озак сайланырга уйлыйлар төсле, ә безнең эш көне ... Аракы бирегез әле". Теге сатып алучы риясыз елмаеп: "Кызларның әчәсе килгәнмени? Алыгыз алла хакы өчен, чиратсыз гына",- диде.

... Тик тегеләрнең җавабы гына көтелмәгәнчә булды. Ханымнар аракы һәм кабымлык өчен акча түләделәр дә, теге сатып алучыга чынлап торып кабәхәт сүз ыргыттылар. Аларның безне сокландырган матурлыгы күз алдыбызда юкка чыкты. Без дә, сатучылар да аптырап калдык. Ә тегеләр, теш арасыннан гына тагын ниндидер бер - ике "тәмле" сүз өстәделәр дә, яшь кенә бер ир - ат белән горур кыяфәттә чыгып та киттеләр. Эшкә дип. "Ярты" кыстырып.

Баксаң, ул ханымнар шушында күршедә генә бер абруйлы гына оешмада эшлиләр икән. Шуннан соң миңа аңлашыларак төште инде. Тик менә нинди урында эшләвең генә башкаларга карата шундый мөнәсәбәттә булырга ирек бирми бит әле.

**Т.ЗАХАРОВА.**
**Нурлат шәһәре.**

---

## ОЛЫЛАР РӘХМӘТ ӘЙТӘ

Җәй башында шикәр заводы җирлегендә салына торган Аллаһы тәгалә йорты - мәчетебезнең манарасын күтәреп кую урамыбызга, мәхәлләбезгә олы ямь кертте. Аны күтәрүчеләргә, гомумән мәчетне төзүчеләргә чын күңелдән рәхмәтләребезне җиткерәсебез килә. Районыбызның бик күп оешмалары, предприятиеләре, хуҗалыкларның булышлыгы инде. Нинди милләт вәкиле булуларына карамастан, үтенечебезне кире какмаска тырыштылар. Рәхмәтебезне бигрәк тә "Нурлатнефтеразведка" ОООсы директоры А.С.Насолдинга җиткерәсе килә. Шул ук предприятиедән Х.И.Әюповка, Р.Р.Мәхмүтовка, анда эшләүче слесарьларга, эретеп ябыштыручыларга һәм башкаларга юллыйбыз. Без, мәчеткә йөрүчеләр, имамыбыз Галиулла углы Йосыф Зәйнетдинов белән берлектә Коръән аятьләре укып, мәчет манарасын ясауда һәм аны урынына урнаштыруда эшләүчеләргә саулык - сәламәтлек теләдек, рәхмәтләребез төшүен теләп дога кылдык. Аллаһы ризалыгы өчен күрсәткән ярдәмнәре өчен бу бәндәләргә изге морад - максудларга ирешергә насыйп булсын иде! Амин!

**Имамыбыз һәм мәчет картлары исеменнән Гыйләҗетдин МОГАЙНЕТДИНОВ. II группа сугыш инвалиды.**

---




# ИСКЕНЕ КАЙТАРСАК?

**Фикер**

Елның - елында бу тегермәнлеккә йон теттерү өчен хатын - кызлар алып барам. Быел анда булганнан соң озак вакытлар җаныма тынычлык иңмәде. Хәтердә балачак истәлекләре яңарды: бирегә, тегермәнгә килеп он тарттырулар, тирән буа суында балыклар сикерүе, ул төбәктәге сурәтләп бирә алмастай матурлык. Дөрес, табигать матурлыгы бүген дә сокланып туймаслык: халык телендә "тридцать пятая мельница" дип йөртелгән бу тирәдә ял базасы төзесәң дә һәркем канәгать калырлык. Әмма сүзебез башка темага бүген: тегермән хакында. Хәзер Кузнецов исемендәге КХА карамагына караган тегермәнлекнең төп корпусы элекке хәлдә диярлек, чөнки 3 катлы таш бина мәңге җимерелмәслек итеп төзелгән. Ә менә янәшәдәге йон теттерү цехы бүген ишелмәсә дә иртәгә һичшиксез аварлык хәлгә җиткән. Складларның да рәвеше шундый. Юкса бит бирелә кешеләр эшлиләр, алар йомышы төшеп килүчеләрне ачык чырай белән каршы алалар. Ул ягымлылык кабул итүче хатын - кыз Лариса Портновадан башлана. Һич иренмичә, килүчеләрнең йомышын тыңлый, хәл - әхвәлләрен сораша. Шундагылардан белдек: өстәвенә, әле ул шул поселоктагы әби - бабайларга почтасын, пенсиясен дә вакытында кайтарып тора икән.Тегермәнчеләр Кузнецов Сергей, Однов Геннадий да һәркемгә булышып торалар.

Йон теттерү цехында эшләүчеләрнең хәле бигрәк тә аяныч безнең карашка: иске бинада үтәли җил йөри, шыксызлык. Әмма анда эшләүче Владимир Макаров та клиентның хәленә керешергә тырыша.

Ә ташландык искелек адым саен очрый. Тегермән ягына чыга торган күпергә шикләнмичә керерлек түгел. Ә бит бар иде бу тегермәннең данлыклы еллары! Бушлай, су көче белән әйләнә торган тегермәндә ничә төрле он тарттырыла, шунда ук йон теттерелә иде. Заманында гөрләп торган тегермәнне эшләтү өчен бүген буа гына буасы юкса... Кыйммәтле электр энергиясе түгәсе дә юк. Аның экологик ягы да файдага гына. Нигә дип соң без бу файдалы кәсепне яңадан торгызмыйбыз икән?

Соңгы баруымда шул хакта уйландым. Бәлки минем бу фикерем җитәкчелекне дә уйланырга һәм гамәли чара күрергә этәрер?

**Н.ШӘЙХИЕВ.**
**Зирекле авылы.**

**Редакциядән:** ***автор язмасы буенча Кузнецов исемендәге КХА идарәсенә шалтыраткач, тегермәнне 3 еллап инде арендаторлар эшләтүе мәгълүм булды. Кем белә, бәлки арендатор Сергей Захаровны да автор күтәргән мәсьәләләр борчыйдыр...***

---

### *Сораулы хат*

## ИШЕГАЛДЫБЫЗ ЮК

Без Школьная урамының 13нче йортында яшибез.Йортыбыздан чыккач ишегалды булмавы безне бик борчый. Керләр эләргә дә урын юк. Өстәвенә, яныбызга 2 гараж салып куйдылар, аларның һәркайсында бензин сала торган мичкәләр бар. Безнең үтенечебез дә шул: бу гаражларны алсыннар иде. Безнең дә бит машиналарыбыз бар, димәк, шундый ук гаражларны безгә дә салып куярга ярый?

**Барлыгы өч имза.**

---

### *Конвертта - шигырьләр*

## ТӨШЛӘРЕМДӘ КҮРЕП УЯНАМ

*Туган якның яшел урманнарын*
*Төшләремдә күреп уянам.*
*Чикерткәләр җырын тыңлап йөреп*
*Болыннардан бетмәс моң алам.*
*Чәчәк исе аңкып торган сөтне*
*Эчәм имеш - басмый сусауны.*
*Әллә инде анда алган көчләр*
*Кайтып күр, дип шулай кушамы?*
*Яшәү дәрте биргән шул төбәктә*
*Калды кайтмас яшьлек елларым.*
*Чулман буйларыннан искән*
*җилләр*
*Зыңгылдата күңел кылларын.*

*Бик күп еллар үткәч мин аңладым:*
*Туган нигез якын күңелгә.*
*Изге Мәккә миңа туган ягым!*
*Нигә җәннәт эзләп йөрергә?*

## МИН ГАШЫЙКМЫН

***(Яшьләрнең куен дәфтәренә)***

*Мин гашыйкмын сиңа - туры әйтәм,*
*Яшермимен шушы серемне.*
*Күңелемдә булган саф сөюдән*
*Мин бәхетле тоям үземне.*
*Нур бөркелә көләч карашыңнан,*
*Шат көлүең - чишмә агуы.*
*Күрсәм сине көнгә берәр мизгел,*
*Арта бара йөрәк януы.*
*Йөрәгемнән аккан наз елгасы*
*Һаман эзли тыныч күлләрен.*
*Гөнаһсыз, пакъ тойгыларым*
*җирдә*
*Тиңдәшсездәй тоя үзләрен.*
*Шуңа дамы мин гашыйкмын*
*сиңа?..*
*Көтеп алам яңа таңнарны...*
*Сине күреп яшәргә көч җыям,*
*Көтмәсәм дә сөю назлары.*

**Наил НӘҖМИЕВ,**
**Яр Чаллы.**

## Якташлар ничек яши?

# МАРС МАКАРОВ ҖИТДИ МУЗЫКА ЯКЛЫ

***"Киек казлар", "Мәк чәчәге", "Каз канаты", "Туган авылым", "Авыл көе" һәм тагын шундый татар җыры классикасына әйләнгән дистәләгән җырлар авторы, композитор, ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре, Казанда яшәүче якташыбыз Марс Макаровның исеме күпләргә таныш. Шушы көннәрдә ул районга кунакка кайткан иде. Редакциягә кергәч, безнең арада кыска гына сөйләшү булды.***

- Киләсе елда миңа 60 яшь тула, алла боерса,- ди ул. Бүгенге мәшәкатьләре дә шуңа әзерләнеп йөрүгә бәйләнгән икән: Казанда бенефисын зурдан оештырырга ниятли һәм аны үткәрүдә туган якларының ярдәменә өметләнә.

Ә гомуми музыкаль тормышына килгәндә, ул хәзер үзенең бар көчен, сәләтен оркестр әсәрләре иҗат итүгә багышлый. Сәхнәләр бер көнлек, җиңел башкарыла һәм кабул ителә торган җырлар белән тулды, ди ул. "Казан радиосы"нда атнасына 2 - 3 тапкыр бара торган "Музыка сәгате" тапшыруында да ул шундый көйләргә, җырларга каршы "көрәш" алып бара, радио тыңлаучыларга җитди музыканы пропагандалый. Аннары татар эстрадасында чикләнгән, тар темалар, әни, мәхәббәт, сагыш темалары да зур урын алды, дип сөйли композитор. Фәүзия Мөхәммәтованың "Нурлат шикәре" шигыренә язылган җырын искелектә, торгынлыкта гаепләп каршы чыгучылар булуын да шул күренеш белән бәйли. Аңа көйне ул 1996 елда яза. Җыр вариантында ул "Ак шикәр иле - Нурлат" дип атала һәм аны Лидия Әхмәтова башкара. Композиторга шул җырны эфирдан ешрак биреп халыкка ишеттерү өчен төрле киртәләрне үтәргә туры килә.

- Шикәр дә икмәк кебек ул, бу хакта бер булса да җыр булырга тиеш, - дип фикер йөртә Марс Андреевич. - Халыкның эчтәлексез җырлар белән мавыгуы бик борчый мине. Алар бит бер генә көнлек, шуңа күрә җырчылар программаларын яңартып торалар да, чөнки һәр яңа җыр онытыла, халык хәтереннән төшеп кала бара.

Әле күптән түгел Алексеевск районында яшәүче Алмаз Әхмәтовның "Хуҗалар тавы" дигән шигыренә көй язган. "Ул романска тартым, аны опера җырчысы башкаруында ишетерсез", - ди композитор.

Җырчылардан Георгий Ибушев, Айдар Фәйзрахманов, Вафирә Гыйззәтуллина, Хәйдәр Бигичевны үз итә. Алар борынгы канунннарыбызны саклыйлар, онытылган җырларны шомартып яңадан сәхнәгә чыгаралар, ул җырлар киләчәк буынга да калачак, дип уйлый.

- Марс Андреевич, туган авылыгыз бүген сездә нинди тәэсирләр тудыра, кардәшләрегез бармы анда?

- Әйе, ерак туганнарым яши анда. Авылда бүген йортлар башка, үзгә, минем балачак хатирәләремдә һаман да салам түбәле өйләр саклана бит әле. Ә менә Чурабатырның хозур табигате шул ук - Әйшәбикә, Әмин елгалары, Кызлар, Аю аланнары мин үскәндәгечә,- ди Марс Андреевич.

Икенче юлы Марс Макаров туган ягына сәнгать мәктәбе ачылу тантанасына кайтырга өметләнә. Музыка дигән сихри дөньяга керергә теләүче балаларны яңа йортка чын, талантлы композитор озатуы уңай символ булыр иде ул...

**Ф.ГАЛИМОВА.**

# Александр Дмитриевич ДМИТРИЕВ

***1998 елның 11 августында авырудан соң сугыш һәм хезмәт ветераны Александр Дмитриевич Дмитриев 76 нчы яшендә вафат булды.***

А.Д.Дмитриев 1923 елның 24 мартында Татарстанның Октябрь районы Вишневая Поляна авылында туган. Александр Дмитриевичның бөтен гомер юлы безнең район белән бәйләнгән. Ветеран кырыс сугыш юллары буйлап та уза, сугыштан соңгы авыр елларны да кичә - 15 ел буе "Ленинский путь" колхозына җитәкчелек итә.

Хезмәт эшчәнлеге чорының соңгы 22 елын Александр Дмитриевич колхоз рәисе урынбасары була, аңа кешеләр белән эшләү кебек җаваплы идеологик эш йөкләнә - ул 20 ел буе "Восход" колхозы башлангыч партия оешмасын җитәкли.

Намуслы хезмәте белән А.Д.Дмитриев колхозның һәм районның авыл хезмәтчәннәре алдында зур абруй казанды. Районның күп халкы аны хуҗалык җитәкчесе, партия вожагы буларак кына түгел, пропагандист, лектор, "Дуслык" район газетасының штаттан тыш актив хәбәрчесе, яшьләрнең зирәк һәм игелекле остазы буларак та яхшы белә иде.

Кайда гына эшләсә дә, А.Д.Дмитриевка һәрчак компетентлык, оешканлык, хезмәт сөючәнлек, максатчанлык, таләпчәнлек, принципиальлек, кешеләргә карата игътибарлы һәм ихтирамлы мөнәсәбәт хас иде.

А.Д.Дмитриевның сугышчан батырлыгы һәм хезмәт эшчәнлеге күп бүләкләр белән билгеләп үтелде.

Александр Дмитриевич Дмитриев турындагы якты истәлек безнең күңелләрдә гомергә сакланыр.

**Ф.С.Сибагатуллин, Ю.В.Терентьев, А.Н.Ельченков, Ф.М.Дәүләтшин, Ф.Р.Ногъманова, Н.Б.Мөлеков, Ф.Н.Гобәйдуллин, Р.Г.Билалов, Н.Х.Абдулли[illegible] Ю.А.Муракаев, И.У.Гыйләҗев, Н.И.Маслаков, В.В.Тарасов, Ф.М.Галимов.**

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Яңа Иглай авылында яшәүче кадерле **әтиебез Габдулла Мотыйгулла улы ГАЛИУЛЛИНга** 14 августта 60, **улы Әмиргә** 30 яшь тула. Без аларны туган көннәре белән котлыйбыз, озын гомер, ныклы сәламәтлек, чиксез шатлык - сөенечләр, кайгысыз көннәр телибез.



**Барлык балалары, килен - кияүләре һәм оныклары исеменнән Әнвәр.**

## ҖӘЙНЕҢ МАТУРЛЫГЫ - ЧӘЧӘКТӘ



*Н.АЗИЗОВ фотосы.*

# БӘХЕТ ӨЧЕН КҮП КИРӘКМЕНИ...

***Быелгы җәй җылыга кинәндерде безне. Яраткан Чирмешәнем турында берничә сүз әйтәсем килүе дә шуңадыр бәлки...***

***

Чирмешән минем өчен үз характеры һәм сокландыргыч хозурлыгы булган җанлы зат кебек. Җәй көне ул аеруча үзенә тартып тора. Кызу көннәрдә, су буендагыдан да рәхәтрәк ял юктыр, мөгаен (йөзә белсәң, әлбәттә).

Күпчелек әти - әниләр су коенырга балалары белән бергәләп киләләр. Яннарында олылар булу балаларга да кыюлык өсти. Чулпанлыларның су коенырга яратып йөри торган урыннары да быел балаларның шау - шуыннан, олыларның елмаюыннан ямьле булып гөрләп торды.

Су коенучы һәркемдә шатлык гормоннары барлыкка килә торгандыр, мөгаен. Чалкан ятып йөзүдән дә рәхәт ни нәрсә бар икән тагын! Төбе тирән елганы тоеп, акрын гына, бар дөньяңны онытып йөзәсең дә йөзәсең. Һәм шул минутларда: "Бәхет өчен күп кирәкмени?!" дип уйлап куясың да инде.

Әле менә бер яшь кенә хатын да миңа әйтеп куйды:

- Кешегә бәхетле булу өчен күп кирәкми.
- Әйе, - дидем мин.
- Балачагыңның каядыр янәшәдә генә йөрүе кирәк,- дип өстәде ул елмаеп.
- Юк, ул яныңда йөзсә яхшырак,- дип сүзгә кушылды почык борынлы бер кыз.

**Г.ПАРГУНЬКИНА.**
**Чулпан авылы.**


## БЕЛДЕРҮЛӘР. РЕКЛАМА. БЕЛДЕРҮЛӘР

### САТАБЫЗ

**Нефтьчеләр урамында йорт.**
Тел.: 5-29-77, кичке 4тән соң.

***

**Аз кешеле гаиләләләр йортында бүлмә.**
Совет ур., 189-45 адресы буенча кичке 5тән соң Гыйззәтуллиннарга мөрәҗәгать итәргә.

***

**"Минск" мотоциклы.** Адрес: Циолковский ур., 44.

***

**Телевышка ягында капиталь гараж.** Тел.: 2-11-24.

***

**547нче ПМК ягында базы белән капиталь гараж.**
Тел.: 5-38-40.

**Чикләнгән җаваплылыктагы "Нурлат кием - салым базары" җәмгыяте 7 кабыргалы шифер сата. Табагы - 18 сум.** Тел.: 5-38-52.

***Район мәдәният йортында "Илдан" фирмасы 18 - 21нче августта 10 процент ташлама белән иртәнге 9дан кичке 5кә кадәр товарларны сату - ярминкәсе уздыра.***

**Сатуда:**
- **төрле мехтан якалы кышкы пальтолар,**
- **мех пальто һәм ярымпальтолар,**
- **мех баш киемнәре,**
- **кайры туннар, мех курткалар,**
- **язгы - көзге пальтолар.**

**ЭШКӘ ЧАКЫРАБЫЗ**
*Нурлат районы МПП ЖКХ сына 5нче разрядлы эретеп - ябыштыручылар кирәк. Хезмәткә түләү - штат расписаниесе буенча.*

## БЕЛДЕРҮЛӘР

### САТАБЫЗ

**Димитров урамында 1нче йорт.**

***

**Кузовы 1994 елда алмаштырылган, үзе 1997 елда капиталь ремонт үткән 1982 елгы ВАЗ - 2106 һәм 9 мең км. юл үткән, 1998 елның маенда чыккан"Газель" (әрҗәле,тентлы).**
Адрес: Көньяк ур., 25, тел.: 2-11-24, 5-19-95.

***

**Совет ур., 195 - 70 адресы буенча ике бүлмәле фатир.** Тел.: 5-24-38, кичке 4тән соң.

***

**Ашыгыч төстә бер бүлмәле фатир.** Тел.: 5-18-66.

***

**Азык - төлек комбинаты ягында капиталь гараж, Завод тыкрыгында төзелеп бетмәгән гараж.**
Тел.: 2-16-98.

***

**Азык - төлек комбинаты каршында базы белән гараж.** Адрес:Гыйматдинов ур., 51 - 16, тел.: 2-24-66.

***

**Некрасовкада дача.** Тел.: 5-25-74.

***

**ВАЗ - 2105.** Урта Камышлыда тел.: 2-35-44.

***

**Төзүчеләр урамында ике бүлмәле фатир, 15 мең сум. Базы, сарае,мунчасы бар.** Адрес: Суворов ур., 5.

***

**Ашыгыч төстә Иске Чаллы авылында дача (НУРБ), НГДУ ЖКХсы ягында базы белән гараж.**
Адрес: Дружба ур., 66 - 42.

***

**Әйбәт хәлдәге, 1995 елгы ВАЗ - 2121.**
"Автозапчасти" кибетенә мөрәҗәгать итәргә.

***

**Кормыш микрорайонында капиталь гараж.**
Тел.: 5-26-39.

***

**Кычытканлы авылында йорт яны корылмалары белән әйбәт хәлдәге агач өй. Бәясе килешү буенча**
Кычытканлыда тел.: 4-42-48.

***

**Азык - төлек базары ягында 2 бүлмәле фатир**
Адрес: 60 лет Октября ур., 9 - 9.

***

**Запас частьларга 30 ат көчле "Запорожец".**
Адрес: Куйбышев ур., 48 - 2, тел.: 3-06 (тимер юл).



БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА.**

Учредительләр:Нурлат район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.

"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Нурлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19. Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.

*ГазетаТатарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2353 данә 3281